СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366) 52-3-93, факс (84366) 52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Кәче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 03 » август 2021 ел **№ 30**

**«Кәче авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Кәче авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Кәче авыл җирлеге Советының 2014 елның 03 ноябрендәге 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 18 апрелендәге 17 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә Кәче авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Кәче авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Кәче авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәне раслау хакында» Кәче авыл җирлеге Советының 2014 елның 03 ноябрендәге 21 номерлы карарына (2016 елның 18 апрелендәге 17 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктның 1.1 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-

биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кереминнән һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганакларыннан артып китсә.»;

1.2. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш кылуга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кереминнән артса, алыш-биреш башкарылырга тиешле акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр Арча муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында законнарда билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәче авыл
җирлеге башлыгы Р.Д.Шаһиәхмәтов